**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

**2020 елның 15 июне** **№ 153**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләрен гамәлдә булуын туктатып тору турында

«2020 елда Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 29 июнендәге 52 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңа Сала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 3 пунктының, 86 статьясындагы 5 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә) гамәлдә булуын 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңа Сала авылы, Үзәк ур., 1,

ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб ур., 14,

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәТатарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кама Тамагы муниципаль районының
Яңа Сала авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районының
Яңа Сала авыл җирлеге Советы рәисе И.Х. Шиһабеев